


Сибгат ХӘКИМ

ТАУЛАР, ТАУЛАР,
МӘҺАБӘТ ЗУР ТАУЛАР...
ӘЙТ, КЕШЕЛӘК, ТОРЫП
ТАРИХТАН:
ӘЛЛӘ ТАУЛАР АЛДАН,
ӘЛЛӘ ЛЕНИН АЛДАН,
ӘЛЛӘ АЛАР БЕРГӘ
КАЛЫККАН?

ТАУЛАР, ТАУЛАР,
МӘҺАБӘТ ЗУР ТАУЛАР...
ӘЙТ, КЕШЕЛӘК, АШЫП
КҮКЛӘРДӘН:
ӘЛЛӘ ТАУЛАР АНЫ,
ӘЛЛӘ ЛЕНИН ТАУНЫ
ҖИЛКӘСЕНӘ БИЕК
КҮТӘРГӘН?

МӘСКӘҮ. Бу арада В. И. Ленинның Үзәк музеенда тамашачылар аеруча күп. Юлбашчыбызга 98 яшь тулу уңае белән монда көнендә унбишәр меңгә якын мәскәүлеләр һәм кунаклар була.
Рәсемдә: музей залларының берсендә мәктәп балалары.

К. Мостафин фотосы. (ТАСС).

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!
Советлар Союзы Коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә әзер бул!

ВСЕГДА ГОТОВ!

Яшь ленинчы

ВЛКСМның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ һәм В. И. ЛЕНИН ИСЕМЕНДӘГЕ ЛЕНИН ОРДЕНЛЫ БӨТЕНСОЮЗ ПИОНЕР ОЕШМАСЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА СОВЕТЫ ОРГАНЫ

№ 31
(1834).
ШИМБӘ,
20 АПРЕЛЬ, 1968 ЕЛ,

1924 елның 10 октябреннан чыга.

Бәясе 1 тиен.

БЕР ЭКСПОНАТ ТАРИХЫ

Ленино-Кокушкинодагы В. И. Ленин музей-йорты илебез пионерлары һәм хезмәт ияләре җибәргән экспонатлар хисабына байый бара.

Узган ел без Ставрополь пионерларыннан тагын бер бүләк алдык. Бу бүләкнең бераз гына тарихы да бар.

Партиянең XXIII съезды барган көннәрдә ставропольлеләр В. И. Ленинның секретаре Л. А. Фотиевага хат җибәргәннәр. Менә ул хатның эчтәлеге:

«Кадерле Лидия Александровна! Ставрополь мәктәпләрендә Ленин музейларын төзүдә Сез зур ярдәм иттегез. Съезд барган бу истәлекле көннәрдә без Сезгә тагын хат язарга булдык. Съезд Президиумы членнарының автографларын алып, безгә җибәрә алмассызмы? Без үзебезнең В. И. Ленин музеенда XXIII съезд делегатларына багышлап аерым бүлек ачмакчы идек. Мөмкин булса, съезд турында истәлекләрегезне дә җибәрегез әле... Җавап көтеп калабыз.

Сезгә зур хөрмәт белән,
Ставрополь пионерлары».

Озак та үтми Ставрополь пионерлары Лидия Александровнадан җавап хаты алалар. «Кадерле яшь дусларым! КПССның XXIII съезды Президиумы членнары, сезгә зур ышаныч белдереп, үзләренең автографларын бирделәр. Әлбәттә, сез бу ышанычны акларсыз, Бөек Ленин исемен югары йөртерсез.

Сезгә зур тарихи әһәмияткә ия булган ул документны җибәрәм. Ләкин миндә бер сорау туа. Бу документ белән башка кешеләрнең дә танышасы килер бит. Бәлки аны В. И. Ленинның Үзәк музеена тапшырырга кирәктер. Бергәләп киңәшегез әле. Әгәр дә минем киңәш буенча эш итсәгез, ул автографлар янына «Бу документ Ставрополь пионерлары соравы буенча төзелде» дигән сүзләр язылыр, ә Үзәк музей сезгә ул документның фотокүчермәсен бирер.

Минем сүзләр белән килешсәгез, аны Мәскәүгә ничек илтү турында уйлашыгыз. Минемчә, бу документны Ставрополь пионерлары делегациясе тантанал ы шартларда тапшырса, әйбәт булыр иде.

Л. ФОТИЕВА.
Мәскәү, 13 апрель, 1966 ел».

...Тиздән Ставрополь шәһәренең 5 нче мәктәп пионерлары бу тарихи документны В. И. Ленинның Үзәк музее хезмәткәрләренә тапшыралар. Хәзер илебездәге күп кенә Ленин музейларында КПССның XXIII съезды Президиумы членнары автографларының фотокүчермәсе саклана.

Җәмилә ИШМОРАТОВА,
Ленино-Кокушкинодагы Ленин музей-йорты директоры.


БЕЗ ЛЕНИНГА ЯЗАБЫЗ

Мәскәү. Кызыл мәйдан. Ленин. Һәркемгә таныш бу исемнәр безнең йөрәкләргә иң изге сүзләр булып кереп урнашканнар. Һәр көнне, һәр сәгатьтә, һәр минутта зурлар да, кечкенәләр дә һаман Ленин янына киләләр. Ленин белән сөйләшәләр. Әле дә ул һәркем күңелендә исән, һәрчак безнең белән бергә яшәп ятучы кебек.

Юлбашчыбызның туган көненә заводлар, фабрикалар, колхозлар, совхозлар зур хезмәт бүләкләре белән киләләр. Пионер отрядлары да бу көнне укуда һәм пионер эшләрендә зур уңышлар белән каршылыйлар. Казандагы 48 нче мәктәп пионерлары «Ленинча укырга, яшәргә һәм эшләргә!» дигән девиз белән яшиләр. Мәктәптә Ленин бүлмәсе бар. Анда экскурсияләр, әңгәмәләр, пионер сборлары үткәрелә. Пионерлар исеменә ГДРдан, Чехословакиядән, Ленинградтан, Мәскәүдән хатлар, бандерольләр килә. Пионерлар үзләре Ульяновскида, Мәскәүдә, Ленинградта булып, В. И. Ленин турында шактый материал туплаганнар. Отрядлар арасында Ленин бүлмәсендә уку хокукы алу өчен ярыш бара.

В. И. Ленин үзе исән вакытта балалардан да, олылардан да бик күп хатлар алган. Пионерлар, октябрятлар Ильичка үзләренең планнары, уйлары, хыяллары турында язганнар.

«Яшь ленинчы» 48 нче мәктәп пионерларына «Син Ленинга нәрсә турында язар идең?» дигән сорау белән мөрәҗәгать иткән иде. Газетаның бу санында — пионерларның хатлары. Тыңлагыз, алар Ленин белән сөйләшәләр.



Владимир Ильич Ленинның бу фотосы уникаль фото һәм әлегә кадәр аның беркайда да басылып чыкканы юк. «Ленин Казанда» фильмын эшләгән режиссер Володя Стрелков аны уңышлы файдаланды. Гомумән, бу фильм фәкать документлардан гына тора һәм Ильичның Казандагы тормышын, аның революцион характеры формалаша башлавын чагылдыра.

ФИЛЬМ ЭШЛӘГӘНДӘ

— Әтием, әтием, киноны ничек ясыйлар? Әтием, экранда кешеләр ничек хәрәкәтләнә?

Тәмам аптырата мине улым Илнур. Ул үзе художество мәктәбендә беренче класста укый. «Мин үскәч художник-мультипликатор булам»,—дип йөри. «Кем соң ул мультипликатор?»—дип сорыйлар аннан иптәш малайлары. — Улмы? Ул... ул... кино ясаучы, — ди Илнур. Мин аны берничә тапкыр эшләгән җиремә — киностудиягә алып барган идем. Хәзер ул иптәш малайларына киноның ничек ясалуы турында үзе аңлаганча, үзенчә сөйләп бирә.

ИЛНУРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ХИКӘЯСЕ

«Әтием минем Казан киностудиясендә эшли. Редактор булып. Беләсезме, редакция нәрсә ул? Әти сөйләде миңа. Редакция—студиянең штабы икән. Бөтен хикмәт шуннан башлана. Редакция нинди фильм төшерергә кирәклеген бик уйлап башта план кора икән. Аннан соң гына төшерә башлыйлар.

Мин беренче барган көнне алар «Ленин Казанда» дигән фильм эшләргә җыеналар иде. Ленин бабай күптән үлгән бит, дип уйлыйм мин. Ничек аның Казанда булуы турында фильм эшли алырлар икән? Операторларны автобус белән озатканнарын үз күзләрем белән күрдем. Әллә нинди аппаратлар, өч аяклы тимерләр, иң күбесе — зур-зур лампалы прожекторлар... Менә мондыйлар алар».

Илнур шунда кулына карандаш алды да прожекторларның нинди булуын кәгазьгә сызып та күрсәтте. Ай-яй малай, — диләр иптәшләре.

ИЛНУРНЫҢ ИКЕНЧЕ ХИКӘЯСЕ

«Әтием белән Ленин бабай турында кино төшергән урынга киттек. Әнә шунда гына инде мин теге олы-олы прожекторларның нигә кирәклеген аңладым. Ленин укыган университетның фәнни китапханәсендә иде бу. Прожекторларны төрле урынга утыртып куйганнар да, оператор командасы белән бер кабызып, бер сүндереп торлар. Якты булмаса, кинопленка чиста чыкмый икән.

Ленин бабай безнең Казан университетында укыган вакытта аны карточкага төшергән булганнар. Оператор белән режиссер (анысы кем булуын мин соңыннан гына белдем) аның шул фоторәсемне архивтан табып алгач әй куандылар, әй куандылар...

Архивтан тагын Ленин бабайны кулга алу турында язылган кәгазьләр, белешмәләр, аны белгән кешеләрнең язып калдырган язмаларын тапканнар. Анда меңләгән папка, йөзләгән киштәләр.

Аннан соң мин операторның университет каршындагы яшь Ульянов һәйкәлен ничек кинога төшергәнен карадым.

Оператор башта, кай җиргә басып төшерим икән дип, урын сайлады. Озак йөрде бу. Иелеп карады, ятып карады, әллә нинди кечкенә арба алып килеп, аңа басып карады. Агач башына да менеп камерасын турылап нәрсәдер күзәтте. Кайчан төшерә башлый, кайчан прожекторларны куеп яктырталар инде, дип торганда: «Эш бетте, әйдәгез кайтабыз»,—диделәр дә әйберләрен автобуска төяделәр һәм без киностудиягә кайтып киттек. Алар инде төшереп бетергәннәр дә икән. Күрәсең, тышта төшергәндә прожектор булмаса да ярый».

Студиядә пленкалар озак эшкәртелә. Башта негатив алына, аннан соң гына экранда карарлык булып өр-яңа пленка чыга, анысын позитив дип атыйлар. Улым бу хакта болай аңлатырга тырыша.

ИЛНУРНЫҢ ӨЧЕНЧЕ ХИКӘЯСЕ

«У-ух, малайлар, зур ул киностудия. Аның кино карый торган җиде залы гына бар. Башта коридор буйлап барасың да барасың, аннан сулга борылып икенче коридорга килеп чыгасың. Аныһыннан бераз баргач, ике яклап бүлмәләр тезелеп киткән. Анда ап-ак халат кигән апалар эшли. Үзләре бик ягымлылар. Аларны монтажчылар дип атыйлар. Биредә позитив пленканы режиссер кушуы буенча кисеп кирәкле урынга кләй белән ябыштырып тезеп баралар икән. Каршыларында бәләкәй генә экран. Мине дә үзләре янына утырттылар. Бер кнопкага басканнар иде, пыяла астыннан кадрлар үтә башлады, алар чын экрандагы кебек хәрәкәтләнәләр. Үзебез төшергән Ленин бабай һәйкәлен дә күрдем, музей залларында йөргән кешеләрне дә таныдым. Ә кайда соң Ленинның яшь чагындагы рәсеме? Анысы башка цехта—мультипликация цехында, диделәр. Мине иң кызыксындырганы әнә шул цех бит инде. Ә мин монтажчылар янында утырам. Алар пыяла астыннан пленканы шудыралар да, зурайткыч пыяла белән бик җентекләп карап, пленканы тураклыйлар. Кызганам пленкаларны. Яннарында ап-ак материядән эшләнгән зур кәрзин. Анда брак чыккан пленканы җыеп баралар икән. Брак дигәненнән дә бик шәп фото эшләп була, дигәннәр иде. Мин монтажчы апалардан берничә кисәк пленка сорап алдым — Ленинлысын. Кайткач мин аны фильмоскоп аша караган идем, бер дигән күренә».

ИЛНУРНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ ХИКӘЯСЕ

«Анда бер цех бар. Ул цехка балаларны түгел, олы кешеләрне дә кертмиләр. Анда тузан бөртеге дә булмаска тиеш икән. Оператор төшереп алып кайткан пленкасын, кара калын кәгазьгә төреп, әнә шул цехка тәрәзә аша гына тапшыра. Аннан ике-өч көнсез чыкмый икән ул. Чыкканда инде... Ә аңа кадәр менә ничек була: пленканы башта бер төрле химикатка салалар. Анда ак әйбер кара булып, карасы ак булып чыга. Шуннан соң аны икенче төрле химикатка салалар... Озак кына тоталар... Шуннан пленка—оператор нәрсә төшергән булса — агы ак, карасы кара булып чыга. Шуннан соң әлеге пленкалар режиссер кулына эләгә.

Мин ул режиссерны күрдем. Ул бүлмә буйлап бик озак уйлап йөри. Шуннан соң янындагы ике ярдәмче монтажчы кызга пленканың кай җиреннән күпме кисеп алырга икәнне әйтә. Шуннан калган пленканы бер-берсенә ябыштыралар да, режиссер бәләкәй экран янына утырып озак итеп карый. Тагын уйлана. Тагын пленка тураклыйлар. Ленин турындагы фильмны әнә шулай ике айга якын кискәләп, ябыштырып азаплапганнар. Чөнки бит ул Ленин! Аның турындагы фильм әйбәт булырга тиеш.

(Ахыры 4 нче биттә.)

Прожекторлар.

ИЛНУР рәсеме.

Абдулла Алиш исемендәге Пионерлар сараена йөрүче балалар Казандагы кайсы предприятиеләр, кайсы учреждениеләр В. И. Ленин исемен йөрткәнен, кайсыларының Ленин ордены белән бүләкләнгәнен белмәкче булалар. Болар: В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, В. И. Ленин исемендәге врачларның белемен күтәрү дәүләт институты, Ленин районы, В. И. Ленин исемендәге җитен комбинаты, В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсе, В. И. Ленин исемендәге 4 нче мәктәп, Ленин урамы, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге стадион... Ленин орденлы Татарстан мех берләшмәсе, Ленин орденлы Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

Яшь эзтабарлар бу предприятие-учреждениеләрнең тарихы белән, эшчеләре-хезмәткәрләре белән таныштылар. Шуннан соң алар ничектер боларның барысына да яңа күз белән, яңача карый башладылар.

Әйдәгез, дуслар, яшь эзтабарлар күргәннәренең кайберләрен генә булса да безгә дә сөйләсеннәр әле.

...Ира Петрова белән Вова Бондаренко безне Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетына алып керәләр.

— Бу университет 1804 елның 16 ноябрендә ачылган, — дип сөйли безгә Ирина. — 1887 елда, Сембер гимназиясен тәмамлагач, Володя Ульянов Казан Император университетының юридик факультетына укырга керә. Ленин укыган чакта монда барлыгы 4 факультет, 918 студент була.

— Ә хәзерге вакытта, — дип дәвам итә Иринаның сүзен Володя Бондаренко, — Казан дәүләт университетының 8 факультетында 9 мең студент белем ала. Безнең университеттан Лобачевский, Бутлеров, Зинин, Лев Толстой, Балакирев, Щапов кебек зур галимнәр, язучылар укып чыкканнар һәм шунда эшләгәннәр.

1924 елда университетка В. И. Ульянов-Ленин исеме бирелә.

Оля Цареградцева врачларның белемен күтәрү дәүләт институты турында сөйләргә тели.

— Бу институт (кыскача — ГИДУВ) Комлев урамындагы 11 нче йортта урнашкан. Аңа 1920 елның 23 апрелендә, В. И. Ленин рөхсәте белән, сәламәтлек саклау халык комиссары Н. А. Семашко (сүз уңаенда әйтик инде — ул да Казан университетында укыган) тарафыннан нигез салына.

1921 елның 9 февралендә исә, юлбашчы үзе исән чакта ук, бу институтка В. И. Ленин исеме бирелә. Игътибар итегез — юлбашчы үзе исән чакта ук. Без бит шундый фактны да беләбез: Ленинга 50 яшь тулу уңае белән доклад башлангач, Владимир Ильич залны ташлап чыгып китә. Ә менә безнең ГИДУВка үзенең исемен бирдертүгә ул каршы килми.

ГИДУВта ел саен илебезнең төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән килгән меңнән артык врач үзенең квалификациясен күтәрә, аның клиникаларында ел саен ун меңнән артык авыру сәламәтләнеп чыга. Институтта эшләүчеләр арасында 17 фәннәр докторы, 54 фәннәр кандидаты бар.

— Ә миңа Ленин орденлы Татарстан мех берләшмәсе турында менә нәрсәләр сөйләделәр, — дип сүзгә кушылды Боря Сергеев. — Уйлап кына карагыз: безнең мех берләшмәсе РСФСРда эшләнә торган мех продукциясенең өчтән берен бирә. 1958 елда исә, Брюссельдә булган Бөтендөнья күргәзмәсендә, ул эшләп чыгарган әйберләр Алтын медаль белән бүләкләнә. Ленин ордены белән Татарстан мех берләшмәсе (ул чакта әле мех комбинаты дип йөртелә) фронтны җылы кием белән бик яхшы тәэмин иткәне өчен 1944 елда бүләкләнгән.

— Миңа Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры турында әйтергә сүз бирсәгез иде! — дип башлый сүзен Рәисә Ногайбәкова. — Кыскача гына тарихы мондый аның: театрның беренче труппасы 1906 елда Габдулла Кариев тарафыннан оештырылган. Труппада 18 үзешчән актер була. Ә хәзер театрда 54 актер эшли, алар арасында РСФСРның халык артистлары, атказанган артистлары, Татарстанның халык артистлары һәм атказанган артистлары бар.

Театрда Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар»ы кебек гүзәл әсәрләр куела. Файдалы һәм кызыклы спектакльләре өчен 1957 елда театр Ленин ордены белән бүләкләнә.

— В. И. Ульянов-Ленин исемендәге стадион хакында әйтми калу дөрес булмас, дип уйлыйм мин, — диде Лена Овсянникова. — Ул 1959 елда ачылган. Стадионга 25 мең тамашачы сыя. Анда бик әйбәт хоккей мәйданы, футбол кыры бар. Барлык спорт бәйрәмнәре һәм халык күп катнаша торган башка төрле бәйрәмнәр шушы стадионда үткәрелә. СССР хезмәт резервларының IV спартакиадасы да шушында булды, бөтен илдән спорт командалары безнең стадионга җыелды.

— В. И. Ленин исемен йөрткән предприятиеләр, мәктәпләр, урамнарның бөтенесе турында берьюлы сөйләп бетереп булмый, — дип дәвам итте сүзен Лена. — Ә менә бездәге үсешне, төзелешне Владимир Ильич үзе күрсә, ни дияр иде икән, дим мин.

С. ИБРАҺИМОВА.

ЛЕНИН ИСЕМЕНДӘГЕ, ЛЕНИН ИСЕМЕ БЕЛӘН...

РЕДАКЦИЯДӘН: Кадерле укучылар, пионерлар, октябрятлар, эзтабарлар! Ә сездә Ленин исемен йөртә торган ниләр бар? Колхозмы ул, совхозмы, мәктәпме, электр станциясеме, урамы, башка берәр предприятиеме? Алар турында «Яшь ленинчы»ны укучыларга нәрсәләр сөйләр идегез?

1887 елда Казан университетында студентлар хәрәкәтендә катнашкан өчен 17 яшьлек студент Володяны Кокушкинога сөргенгә җибәрәләр. Кокушкинодагы бу агач йортның бер бүлмәсендә В. И. Ленин 1887—1888 елларның салкын кышын үткәрә.

Н. СЕДОВ фотосы.

БЕЗ ЛЕНИНГА ЯЗАБЫЗ

Кадерле Ленин!

Элекке татар кызларының язмышлары турында Сез беләсез инде. Алар иртә таңнан кичкә кадәр эшләсәләр дә ачлы-туклы яшәгәннәр. Көн яктысын күрмәгәннәр. Мондый тормышны мин китаплардан укып кына беләм. Үземне андый фаҗигале тормыш корбаннары белән чагыштырып карарга да батырчылык итмим. Иптәш Ленин, мин Советлар илендә яшәвем белән горурланам. Тәпле белем алырга тырышам. «Укырга, укырга, укырга!» Сезнең бу сүзләрегез һәрвакыт яңгырап тора кебек. Сез шатлана аласыз. Хәзер илебездәге халыкның өчтән ике өлеше укый. Туган шәһәрем Казанда 11 югары уку йорты бар. Училищелар, техникумнар да дистәләрчә. Мин Сезгә татар халкының бүгенгесе, аның культурасы турында тагын да күбрәк итеп язармын әле.

Рәисә ВИЛДАНОВА.

Владимир Ильич!

50 ел эчендә Туган илебез зур уңышларга иреште. Билгеле, бу уңыш җиңел генә килмәде. Гражданнар сугышы, коллективлашу, илне төзеклендерү чоры, тагын сугыш — менә совет халкы үткән данлы җиңү юлы. Илебезгә азат тормыш яулап алуда безнең әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез зур батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Үткән буынның традицияләрен без дәвам итәргә тырышабыз.

Безнең кайберләребез «хәзерге вакытта батырлык эшләп булмый инде» дигән ялгыш фикердә торалар әле. Батырлыкка һәрвакыт урын бар. Мин үзем үсеп җиткәч очучы булырга, космик киңлекләрне яуларга телим. Бу теләккә ирешү өчен, әлбәттә, күп белергә, күп укырга, һәр фәннәре тик «5»ле билгеләренә генә үзләштерергә кирәк. Максатыма ирешү өчен мин тырышып укыйм, спорт белән шөгыльләнәм.

Мин тагын музыка, шигырь тыңларга яратам. Кайвакыт үзем дә шигырь язгалыйм.

Олег СМИРНОВ.

Кадерле Владимир Ильич!

Мин V класста укыйм. Кайбер көннәрне дәрескә әзерлексез киләм. Мондый көннәрне миңа укытучым, иптәшләрем алдында бик читен була.

Беркөнне мин арифметикадан өйгә бирелгән мәсьәләне, укытучы сизмәс әле дип, иптәшемнән күчергән идем. Күчерүен күчердем. Ләкин укытучыга ул мәсьәләнең чишелешен аңлатып бирә алмадым. Укытучы миңа «2»ле куйды. Мин моның өчен укытучыма үпкәләп тә йөрдем. Соңыннан ялгышымны төшендем.

Хәзер мин арифметика дәресенә һәркөнне тулы әзерлек белән килергә тырышам. *Киләсе уку елында башка* фәннәр буенча да билгеләрем югары булыр дип ышанам.

Тәлгать БИКМУЛЛИН.

Тынлык. Әкрен генә яңгыр ява. Бары тик ай гына, болытлар пәрдәсен ачып, җиргә көмеш нурларын сибә. Аның нурлары, урамнардагы электр лампочкаларының төрле төстәге яктылыгы белән бергә кушылып, аеруча матур җемелди. Урамнарда утлар — Сезнең утлар балкый, Ильич!

ГОЭЛРО планы бөтен дөньяны гаҗәпкә калдырган иде. Бу план буенча илебездә 10—15 ел эчендә гомуми егәрлеге 1 миллион 500 мең киловатт булган утыз электростанция төзү күздә тотылды. Бу план срогыннан элек үтәлде. Хәзер бер Братск ГЭСы гына да 3 миллион 600 мең киловатт электроэнергия бирә...

Әйе, илебез зур адымнар белән алга бара. Моңа шатланам да, гаҗәпләнәм дә мин. Гаҗәпләнмәслек тә түгел бит. Нинди генә могҗизалар тудырылмый безнең илдә! Бу эшләрдә илебезнең хатын-кызлары да катнаша.

Мин шофер булырга, яңа ГЭСлар төзүдә катнашырга телим. Ләкин иптәшләрем дә, әти-әнием дә минем теләгемне хуп күрмиләр. Классташ малайлар да: «Кызлар профессиясемени ул», — диләр. Кайчакта алар белән бу хакта бәхәсләшәм дә. Урамда я балчык, я кирпеч төягән машинаны йөртүче хатын-кыз шоферларны да күрсәтеп карыйм мин аларга. Миңа киңәш бирсәгез иде, Ильич. Аларга бу хакта ничек аңлатырга икән?

Гүзәл ВӘЛИЕВА.

Хөрмәтле Ленин бабай!

Менә инде сугыш бетүгә 20 елдан артык вакыт үтте. Мин сугыш фаҗигасен үз күзем белән күрмәсәм дә, үз җилкәмдә татымасам да, әти-әниемнең, апамның сөйләүләре буенча күз алдыма ачык китерәм. Әтиемнең аркасына кергән дошман пулясы йөрәгемне бигрәк тә әрнетте. Ул пуляны тәҗрибәле врачлар әле узган ел гына алдылар. Әйе, сугыш яралары әле төзәлеп бетмәгән... Җир йөзендә яшәүче халыкларның күбесе сугышка каршы чыгалар. Америка сугыш чукмарлары Вьетнам шәһәрләрен, авылларын бомбага тоталар, картларны, балаларны үтерәләр. Халыкка каршы агулы газлар җибәрәләр. Авызлыклыйсы иде ул сугыш чукмарларын. Ничек итеп? Мин әле бу сорауга җавап тапмадым. Шулай да планетадагы барлык кешеләрне дә дуслаштыра, бер-берсе белән уртак тел таба торган ниндидер тылсымлы сүз уйлап табасы иде дип уйлыйм мин. Минем уем менә шундый, кадерле Ильич!

Илдар САДЫЙКОВ.

Менә алар юлбашчыбыз В. И. Ленинга хат язган пионерларның сигезе: Фәридә Сафиуллина, Рәисә Вилданова, Гүзәл Вәлиева, Гүзәл Сабирова, Люба Прохорова, Олег Смирнов, Тәлгать Бикмуллин, Зина Казначеева. Алар укуда да сынатмыйлар, пионер эшләрендә дә актив катнашалар.

Н. СЕДОВ фотосы.

Җавапларыгызны тикшерегез

Кадере октябрятлар!

Сезн өчен чыга торган «Алмаі газетасының узган санынд без «Пионерстан»га сәяхәті дәвам иттерергә чакырган дек. Анда В. И. Ленин турынд җиде сорау бирелде. Сораулга бик күп укучылардан аваплар килде. Күбегез дөр һәм тулы җаваплар язып бәргәнсез. Хәзер шул җаваплагызның дөреслеген тикшерез:

1. В димир Ильич Ульянов (Ленин 1870 елның 10 апреләндә ңача 22 нче апрельдә) Ид буендагы Сембер шәһәренд уган. Хәзер бу шәһәр юлбаш быз хөрмәтенә Ульяновск п йөртелә.

2. кенә Володя шау-шулы, хә кәтчән уеннар уйнарга ярат ан. Шахмат, крокет, кара т к, качышлы, колгааякта йөрү — болар Володя уйнаган уеннар. Ул җәй көннәрендә су коенган, кыш көннәрендә оста итеп тимераякта шуган. Үзеннән кечкенә балаларга уенчыклар ясап бирергә яраткан. Нинди генә уенда катнашса да Володя һәрвакыт гадел булуны таләп иткән һәм, әгәр уенда зур бәхәс килеп чыкса яки балалар сугыша башласалар, уенны туктатып «бу уен түгел, бу — тәртипсезлек, мин катнашмыйм», дип белдергән.


3. Владимир Ильич малай чагында ук рояльдә уйнарга өйрәнә. 8 яшендә ул балалар өчен язылган пьесаларны бик оста итеп уйный. Владимир Ильич гомере буена музыка тыңларга бик яраткан һәм аны яхшы аңлый торган булган. Әле бала чагында ук бүре ашап киткән кәҗә бәтиләре турындагы җырны бик кызганып, ышанып тыңлаган. Үсә төшкәч әнисенә кушылып «Аскольд кабере» операсыннан өзекләр җырлаган. Языковның «Йөзүче» дигән җырын, «Фауст» операсыннан Валентин ариясен башкарган. Рус халкының «Дубинушка» дигән җырын, революцион җырлардан «Варшавянка»ны һәм «Интернационал»ны, П. И. Чайковскийның симфоник әсәрләрен бик яратып тыңлаган. Ә Л. Бетховенның «Апассионата»сын В. И. Ленин кеше иҗат итә алган могҗиза дип атаган.

4. Ильич тормышына багышланган кинофильмнар: «Ульяновлар семьясы», «Ана йөрәге», «Ленин Октябрьда», «Ленин 1918 елда», «Мылтыклы кеше», «Зәңгәр дәфтәр», «Ленин Польшада», «Бер планетада» һ. б.

5. В. И. Ленин турында нинди китаплар укыганыгыз бар? Бу сорауга җавап биргән укучыларның күбесе түбәндәге китапларны санап чыкканнар: М. Ногманның «Кокушкино таңнары» поэмасы, С. Михалковның «Ленин музеенда», Бонч-Бруевичның «Ленин һәм балалар», М. Шагинянның «Ульяновлар семьясы» дигән китаплары һәм «Ленин турында хикәяләр».

Алтынчы һәм җиденче сорауларга җавап язганда укучылар үз районнарындагы В. И. Ленин исеме белән аталган колхозларны һәм үз авылларындагы Ленин ордены белән бүләкләнгән кешеләрне искә алганнар.

Сорауларга җавап җибәргән һәр укучыга редакция зур рәхмәт белдерә.



КУҢЕЛЕМ ЛЕНИН БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘ

Юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел булу уңае белән «Яшь ленинчы» газетасы «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән темага конкурс ача. Конкурска җибәргән шигырьләр, рәсемнәр, хикәяләр яки башка төрле язмалар эчтәлегендә укучының бүген Ленинга күрсәтергә, Ленинга әйтергә теләгән фикере ятарга тиеш. Бу фикер укучының мәктәбе, торган урыны, дуслары-танышлары турында булыр, яисә тынычлык, туган ил, бүгенге төзелешләр һәм, гомумән, бүгенге дөнья кешесе, укучы үзе, аның киләчәккә өметләре булырга мөмкин.

Ашыкмыйча, уйлап язылган, газета битләрендә урын алырлык әйберләр көтәбез.


Конкурс ике ел дәвам итә. Беренче йомгак 1969 елның 22 апрелендә һәм икенче йомгак 1970 елның 22 апрелендә — В. И. Ленин туганга 100 ел тулгач ясалачак. Конкурска нәтиҗә ясаучы жюри составына түбәндәге кешеләр керә: Сибгат Хәким, Әмирхан Еники, Тавил Хаҗиәхмәтов, Равил Фәйзуллин, Николай Седов.

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты бинасында иң изге урыннарның берсе — юлбашчыбыз В. И. Ленин укыган бүлмә. Университетның хәзерге хуҗалары — студентлар һәм укытучылар мондагы һәр нәрсәне күз алмасыдай саклап тоталар.

* * *

Казандагы В. И. Ленин музей-йортына көн саен йөзләрчә кеше килә. Монда зурлар да, кечкенәләр дә Ильич белән үзләренең уй-хисләрен уртаклашалар.

РӘСЕМДӘ: Ленин музей-йорты ремонттан соң.



В. И. ЛЕНИН БҮЛМӘЛӘРЕНӘ

СМОТР БАРА

Юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә В. И. Ленин исемендәге Ленин орденлы Бөтенсоюз пионер оешмасының Республика Советы, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясе һәм Республика яшь туристлар станциясе мәктәпләрдәге Ленин бүлмәләренә, залларына смотр игълан иткән иде. Смотр 3 этапта бара. Аның I этабына йомгак шушы елның 19 апрелендә ясалды.

Смотр игълан ителгәнгә 3 айга якын вакыт үтте. Бу чор эчендә мәктәпләрдәге Ленин бүлмәсе советлары, дружина советлары, смотрга кушылып, шактый эш башкарырга өлгерделәр. Кукмарадагы 1 нче, Бөгелмәдәге 6 нчы, Октябрь районының Күлбай Мораса, Чүпрәле районының Иске Чокалы, Саба районының Алан, Казандагы 48 нче, 51 нче мәктәп пионерлары үз дружиналарындагы Ленин бүлмәләрен яңа экспонатлар белән баету өстендә эшлиләр, туган ягыбызның Совет власте елларында ничек үзгәрүен, Ильич васыятьләренең ничек тормышка ашуын өйрәнәләр, күренекле кешеләр белән очрашулар үткәрәләр.

Смотр штабының Актаныш, Апас, Аксубай, Мамадыш, Мөслим, Чирмешән районы мәктәпләреннән смотрга кушылу турында бер генә хәбәр дә алганы юк.

Смотрның II этабы — 1969 елның 20 апрелендә, ә III этабы 1970 елның 22 апрелендә тәмамлана. Смотрда җиңеп чыгучыларны бүләкләр көтә.

Ярышка кушылуыгыз турында безгә хәбәрләр языгыз.

ФИЛЬМ ЭШЛӘГӘНДӘ

(Ахыры. Башы 2—3 нче битләрдә.)

Аннан соң без мультипликация цехына megдек. Ул икенче катта. Монда инде керергә дә, туйганчы карарга да ярый. Шушы цехтагы аппаратларның ничек эшләгәнен карап торсаң, кино экранындагы кешеләрнең ничек хәрәкәткә килүен ап-ачык аңлыйсың. Аның хикмәте бик гади икән: мәсәлән, стена календарен алыгыз да аның һәр бите саен бер үк рәсемне кабатлап ясап чыгыгыз. Ләкин һәр биттәге рәсем бер-берсеннән бераз гына аерылып торсын. Әйтик, берсендә кулы асылынып тора. Икенче биттә әз генә күтәрелгән. Өченчесендә — күбрәк. Шулай итеп бер үк рәсемне ун-унбиш битнең читенә ясап чыккач, календарьны кулыгызга алып аның рәсем ясалган битләрен бик тизләк белән актарыгыз. Сез ясаган кеше рәсеме хәрәкәткә килгән кебек була.

Мультфильмнардагы курчаклар да шулай хәрәкәткә киләләр икән.

...Ә беләсезме, фотокарточкадагы рәсемне барыбер хәрәкәткә китереп булмый. Аларны яңадан пленкага төшереп экранга гына чыгаралар. Ленин бабайның ничек итеп йөреп киткәнен күрәсем килгән иде».


«Ленин Казанда» фильмы инде эшләнеп бетте. Ул бөтенсоюз экранына кабул ителде. Безнең студия хәзер бөек пролетар язучысы Максим Горькийның Казанда булуы турында фильм эшли башлый. Сценарий язудан алып фильм булып чыкканчы әллә никадәр гомер үтә билгеле. Борчыласың, газапланасың, үртәләсең. Ә соңыннан инде, фильм эшләнеп беткәч... тынычланасың дип әйтүне көтмәгез. Тамашачы ничек кабул итәр икән, нинди бәя бирер икән, дип тагын кайгыга төшәсең. Тамашачының төрлесе бар. Зурысы, кечкенәсе...

Мирхәт ХӨСНИМӘРДӘНОВ.



Рәфгать ӘХМӘТҖАН

ЧИТТӘН ТОРЫП



Газетабызның 24 нче санында без Татарстан чемпионы Наил Мөхәммәтҗанов белән укучылар арасында читтән торып шахмат партиясе башлап җибәргән идек. 28 нче санда шахмат буенча мастерлыкка кандидат Наил абыегыз икенче йөрешне ясады. Күпчелек укучылар җавап итеп А в8—с6 йөрешен язып җибәрделәр. Партия дәвам итә.

Наил Мөхәммәтҗанов — укучылар.

1. e2—e4 e7—e5
2. Ag1—f3 Ab8—c6.
3. d2—d4.

Хәзер, дуслар, сезнең йөреш! Җаваплар көтәбез.

ИЛДУСНЫҢ БЕРЕНЧЕ СӘЯХӘТЕ

(Дәвамы. Башы газетабызның 23, 24, 26, 27, 28, 29, 30 нчы саннарында.)

Бераз торгач бик
аптырап,
Төрле ямьсез уйлар
уйлап,
Карап чыкты ул утрауны,
«Флораны һәм Фаунаны».
Зур түгел утрау
зурлыкка:
Алты чакрым озынлыкка
Һәм киңлеккә булыр
дүрт-биш,
Һәм юк түгел
җиләк-җимеш,
Очрый төрле кикләр дә.
Юанып бу кызыкларга,
Илдус һич тә тормады
буш —
Ботаклардан корды куыш.
Ильясның башмагын киеп,
Карады диңгезгә керен:
Дулкын-дулкын,
бик селкетә,
Аякларның хәле бетә...
Икенче көн Илдус иртән
Күзен ачса — гаҗәп
икән:
Картлар кайтып
җиткәннәр бит,
Куышта ял итәләр бит.
Курку белән кинәт болар
Яшүсмергә баш ордылар:
— Я, кодрәтле,
ибне-Альберт,
Кичер безне һәм ярдәм ит.
Тыңламадык синең сүзне,
Җәзалады язмыш безне.
Таягыбыз тамырланмый,
Теләгебез кабулланмый...
Хәзер инде башчыбыз
бул,
Киңәшең бир һәм күрсәт
юл!
Илдус моңа хәйран калып,
Торды сүз әйтми,
тукталып:
«Ни дип мине уйлый
болар?
Сәер булган
борынгылар?!
Нигә соң?
Әһә... димәк,
«Чын пәйгамбәр»
булу кирәк!»
Һәм ул торып һәм тураеп,
Шәп тәс алып, кукыраеп,
Тантаналы тавыш белән
Сүз башлады:
— Әмер бирәм!
Галим рухын тынычларга
Кирәк шундый юл
эзләргә —
Яусын яңгыр, иссен
җилләр,
Яшәрсеннәр сары җирләр,
Суык яклар төрелсеннәр,
Эссе җилләр
сүрелсеннәр.
Хаттап белән Ильяс
шуның
Эзләсеннәр хәзер юлын.
Шуннан таяк тамырланыр,
Җан өрелер, яфрак ярыр.
Вәкарь[1] белән тыңлап
Хаттап
Ильяска сүз кушты атап:
— Әйдә, кардәш, уйлыйк
әле,
Хәл итик бу мәсьәләне!
Уйчан, сабыр, сүзсез
Ильяс
Риза булып селекте баш,
Формулалар язып комга
Тотындылар уйлашырга:
Табарга дип, чүлләр хәлен
Хәл итүнең бер әмәлен.
Ихтирамлы Илдус исә
Җилән белән җилеп китә,
Тарихчыга бара туры
Һәм аңарга әйтә шуны:
— Тиздән, — ди ул, —
бар чүлләргә
Явым булыр. Күп илләргә
Җиткерергә иде хәбәр —
Начар булыр белмәсәләр.
Тик тарихчы күзләренә
Яшь чыкканчы көлә генә:
— Ну әкәмәт үзең малай,
Кавын башың хыялга
бай!
Китә Илдус. Их, ни
кылсын,
Кемгә әйтеп
ышандырсын?

[1] Вәкарь — олы сыманлык, сабыр акыллылык.

БЕЗНЕҢ АДРЕС: г. Казань, ул. Баумана, 19. Редакция газеты «Яшь ленинчы». ТЕЛЕФОННАР: редактор — 2-56-71; җаваплы секретарь — 2-60-05; әдәбият-сәнгать, хатлар бүлекләре — 2-17-78; пионерлар һәм мәктәп, фән-техника һәм спорт бүлекләре — 2-47-30.

Редактор В. ИХСАНОВА.

ПФ 01165. Заказ 1067. Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Тиражы — 100500.